КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 август г.Казань № 1033

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Белем бирүнең сыйфатын яхшырту һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы; 2023 ел, 3 февраль, 92 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Безнең яңа укытучы».»;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Безнең яңа укытучы» гранты турындагы нигезләмәне.»;

әлеге карарга «Безнең яңа укытучы» гранты турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге карары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 август, 708 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 август, 1033 нче
карары редакциясендә)

«Безнең яңа укытучы» гранты турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмәдә «Безнең яңа укытучы» грантын (алга таба – грант) бирү максатлары, шартлары һәм механизмы билгеләнә.

2. Грантлар бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Нигезләмә буенча грантлар бирү максатына бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

грант алырга теләүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Министрлыкның ведомство буйсынуында булган муниципаль һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының Россия Федерациясе гражданнары булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән, грант алуга заявка (алга таба – заявка) бирү вакытына 35 яше тулмаган һәм белгечлеге буенча кимендә өч ел педагогик эшчәнлек стажы булган, «Мәгариф һәм педагогика фәннәре» югары белем бирүне һәм урта һөнәри белем бирү белгечлекләрен әзерләү юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре кысаларында яки укытыла торган предметка туры килә торган өлкәдә югары белеме яки урта һөнәри белеме йә белем бирү оешмасындагы эшчәнлек юнәлеше буенча югары белеме яки урта һөнәри белеме һәм өстәмә һөнәри белеме булган педагогик хезмәткәрләре (алга таба – педагогик хезмәткәрләр);

эш бирүче (заявка бирүче) – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Министрлыкның ведомство буйсынуында булган муниципаль һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмасы;

грант алучы – конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба – сайлап алу) йомгаклары буенча грант бирү турында карар кабул ителгән грант алырга теләүче;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Министрлыкның ведомство буйсынуында булган муниципаль һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының төп эш урыны буенча «укытучы» дигән төп вазыйфа биләүче педагогик хезмәткәрләренә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителә.

4. Грантның күләме (G) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$G = V \times N,$$

монда:

V – ай саен бирелә торган 10,0 мең сумга тигез түләү күләме;

N – җәйге чорны (июнь – август) исәпкә алмыйча, 27 айга тигез грант түләү срогы.

Ел саен иң күбе 200 грант бирелә.

Грант педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашырган чор өчен грант алучыга грант бирү турындагы килешүдә (алга таба – Килешү) билгеләгән тәртиптә һәм срокларда грант күләме чикләрендә тигез өлешләр белән түләнелә.

5. Грант бирү максатлары:

педагогик хезмәткәрләргә кадрлар кытлыгын бетерү;

уку һәм дәрестән тыш уку эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проектны гамәлгә ашыру кысаларында укыту-тәрбия бирү барышын камилләштерү;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Министрлыкның ведомство буйсынуында булган, «Безнең яңа укытучы» грантында җиңү вакытына педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашырган муниципаль һәм дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрне беркетү.

Грант бирү бурычлары:

перспективалы педагогик хезмәткәрләрне ачыклау, аларга ярдәм күрсәтү һәм бүләкләү;

гомуми белем бирү учреждениесе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен педагогик хезмәткәрләрне һөнәри үстерүне мотивацияләү;

укытучының һөнәрен популярлаштыру һәм аның абруен күтәрү;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри потенциалын үстерү.

6. Грант бирү шартлары:

сайлап алуда җиңү;

педагогик эшчәнлекне кимендә бер тариф ставкасы күләмендә гамәлгә ашыру;

грант алырга теләүченең урта һөнәри һәм (яисә) югары белем турындагы һәм (яисә) квалификациясе турындагы документның эш бирүчедә укытыла торган укыту предметына һәм аның педагогик эшчәнлегенә туры килүе;

эш бирүчедә грант түләнә торган тулы срок дәвамында педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

грант алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавы;

грант алырга теләүче «Безнең яңа укытучы» грантын алучы булмау.

7. Сайлап алу «Безнең яңа укытучы» грантын алуга конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әгәр утырышта конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, конкурс комиссиясе утырышы тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карары кабул ителгән дип санала, әгәр аның өчен тавыш бирүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелеге тавыш бирсә һәм шул ук вакытта утырышта конкурс

комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 50 проценты катнашса.

Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Конкурс комиссиясе составы, сайлап алуны уздыру тәртибе, сайлап алу критерийлары, заявкаларны кабул итү сроклары һәм сайлап алуны уздыру сроклары, Министрлык, грант алучы һәм эш бирүче арасында Килешү формасы Министрлык тарафыннан раслана.

8. Министрлык:

сайлап алу өчен документларны кабул итә башлау датасына кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турындагы, грант алырга теләүчеләргә карата таләпләр, сайлап алу сроклары турындагы мәгълүматны, шулай ук сайлап алу тәмамланган датадан соң җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу йомгаклары турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгаруны тәэмин итә. Сайлап алу турындагы мәгълүматта шулай ук заявкаларны кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыручы оператор, аның урнашу урыны турында белешмә, электрон почта адресы, оператор вәкиленең элемтәгә керү өчен телефон номеры күрсәтелә;

сайлап алуны оештыруны һәм уздыруны, җиңүчеләрне билгеләүне тәэмин итә;

грант бирү турында йә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм грант бирү турындагы карарны Министрлык боерыгы белән раслый;

грант алучы һәм эш бирүче белән Килешү төзи.

9. Заявкаларны кабул итү һәм теркәү өчен Министрлык Министрлыкның ведомство буйсынуындагы оешмалар арасыннан операторны билгели. Сайлап алуда катнашу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Министрлыкның ведомство буйсынуындагы дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм Татарстан Республикасы мәгариф белән идарә итү муниципаль органнары җитәкчеләре операторга түбәндәге документларны һәм материалларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча заявка;

әлеге Нигезләмәнең кушымтасында бирелгән форма буенча уку һәм дәрестән тыш уку эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проект (алга таба – индивидуаль проект);

грант алырга теләүченең Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы;

грант алырга теләүче паспорты күчермәсе;

эш бирүче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белем һәм (яисә) квалификация турында диплом күчермәсе;

грант алырга теләүченең эш урыны буенча таныкланган хезмәт кенәгәсе яисә тиешле рәвештә таныкланган электрон хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

кәгазьдә һәм (яисә) электрон мәгълүмат саклагычта грант алырга теләүченең һөнәри казанышлары турында мәгълүмат бирелгән, җитәкче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белешмә кәгазе (раслый торган документларны теркәп);

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият җыемнары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турындагы белешмә кәгазе.

Грант алырга теләүче тарафыннан белешмә кәгазе заявка бирелгән датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча алынырга тиеш.

Заявкаларны кабул итү һәм теркәү өчен Министрлык Министрлыкның ведомство буйсынуындагы оешмалар арасыннан операторны билгели. Тиешле техник мөмкинлекләр булганда, Министрлык карары буенча заявкаларны бирү Россия Федерациясе законнары (шул исәптән шәхси мәгълүматларны саклау өлкәсендә) таләпләрен үтәү шарты белән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып оештырылырга мөмкин. Сайлап алуга тапшырылган документлар һәм материаллар кире кайтарылмый.

10. Операторга кергән заявка кергән көннән бер эш көне эчендә теркәүгә алына.

11. Заявкаларны карап тикшерү конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң 10 эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 9 пункты нигезендә тапшырылган документларны һәм материалларны карап тикшерә.

12. Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

документларны һәм материалларны тапшырмау (тулы комплект итеп тапшырмау) яисә алар әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килмәү;

бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

заявканы һәм (яисә) документларны заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган датадан соң тапшыру.

Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашудан баш тартылган очракта, әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә оператор заявка бирүчегә һәм грант алырга теләүчегә гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына бу хакта хәбәрнамә җибәрә.

13. Сайлап алу әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:

норматив-хокукый, укыту-методик һәм предмет бөенча белемнәр дәрәҗәсен билгеләүгә юнәлдерелгән тест узу;

грант алырга теләүченең түбәндәге критерийларга туры килүен билгеләүгә юнәлдерелгән һөнәри-психологик әңгәмә узу:

һөнәри яраклылык дәрәҗәсе (укытучылар эшчәнлегенә мотивация һәм әзерлек, укыту методикаларын белү, балаларның психофизик үзенчәлекләрен белү);

педагогик осталык дәрәҗәсе (уку материалын бәян итүгә сәләт, оештыру сәләтләре, үз-үзеңне тоту реакцияләре, мөстәкыйльлек);

һөнәри планлаштыруга сәләт (максатларны төгәл кую һәм өстенлекле бурычларны төгәл билгеләү; уку дәресләрен үткәргәндә чараларны, ысулларны һәм һөнәри алымнарны сайлау максатка ярашлы булу);

индивидуаль проектның булуы һәм эчтәлеге.

14. Сайлап алу йомгаклары буенча грант алырга теләүченең җыелган баллар кими бару тәртибендә ранжланган исемлеге төзелә. Сайлап алуда җиңүчеләр дип сайлап алу йомгаклары буенча иң күп балл җыйган, ранжирланган исемлектә 1 нче урыннан 200 нче урын алган грант алырга теләүчеләр таныла.

Әгәр грант алырга теләүчеләр тарафыннан бер үк санда баллар җыелган булса, конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 7 пункты нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча бер үк санда баллар җыйган грант алырга теләүчеләр

ачыклангannan соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә торган ачык тавыш бирү юлы белән билгеләнә.

15. Грант Министрлык белән Министрлык тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

16. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максатлары;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

грант түләүне туктатып тору, туктату очраклары һәм тәртибе;

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант алучының әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән грант бирү шартларын үтәү буенча йөкләмәсе;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

грант алучының Килешү төзелгән датадан грант түләү срогы дәвамында эш бирүчедә хезмәт педагогик эшчәнлеген башкаруга йөкләмәсе;

грант алучының өч эш көне эчендә Министрлыкка грант бирү срогы чыкканга кадәр эш бирүче белән хезмәт килешүен өзү турында хәбәр итү йөкләмәсе.

Грант түләү срогы дәвамында эш бирүчене алыштыру каралмый.

17. Грант алучының йөклелек һәм бала табу буенча ялда булу, өч яше тулганга кадәр бала карау буенча ялда булу чорында грант түләү туктатып торыла һәм грант алучы тиешле ялдан чыкканнан соң яңадан түләнә башлый.

Грантны түләү грант алучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакырылган очракта туктатыла, ә элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый. Грант алучы срокты хәрби хезмәт үтү тәмамланганнан соң мәгариф оешмасына кире кайткан очракта, төзелгән Килешү шартлары нигезендә грант алучыдан Министрлыкка хезмәт шартнамәсе төзү турында һәм Килешүгә теркәлә торган форма буенча Килешү гамәлен яңарту турында хәбәрнамә килгән календарь айдан грант яңадан түләнә башлый.

Грант алучы тарафыннан грант бирү срогы тәмамланганга кадәр эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә, әлеге шартнамә өзелгән вакыттан грант түләү туктатыла. Элек түләнгән грант суммасы, хезмәт шартнамәсе өзелгән датадан өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Хәрби хезмәткәр булган ире (хатыны) яшәү урынын алыштыруга бәйле рәвештә, грант алучы тарафыннан грант бирү срогы чыкканга кадәр хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, әлеге шартнамә өзелгән вакыттан грант түләү туктатыла, ә элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый.

18. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Министрлыкның ведомство буйсынуында булган дәүләт гомуми белем бирү оешмалары белән хезмәт

килешүләре төзегән грант алучыларга грант бирү Россия кредит оешмаларында ачылган грант алучыларның шәхси счетларына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмалары белән хезмәт килешүләре төзегән грант алучыларга грант бирү максатларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә башка бюджетара трансфертлар бирелә.

19. Грант алучылар Министерст тарафыннан билгеләнгән операторга Килешүдә билгеләнгән форма буенча һәм срокта, әмма грант бирелгән датадан өченче уку елының 31 маеннан да соңга калмыйча, грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап булып торган, эш бирүче белән килештерелгән индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Грант алучылар ел саен, грант бирелгән датадан беренче һәм икенче уку елының 25 маена кадәр заявка бирүче тарафыннан төзелә торган эксперт комиссиясенә индивидуаль проектны яклау рәвешендә индивидуаль проектны гамәлгә ашыруның арадаш этаплары турында хисап тапшыра.

Индивидуаль проектны гамәлгә ашыру буенча эксперт комиссиясе составы, аның эш тәртибе эш бирүчене гамәлгә куючы тарафыннан раслана.

Индивидуаль проектны гамәлгә ашыру буенча эксперт комиссиясе составына муниципаль берәмлек башкарма комитетының методик хезмәтләре һәм мәгариф бүлеге (идарәсе) вәкилләре, фәнни һәм педагогик җәмәгатьчелек, педагогик хезмәткәрләр профсоюзы вәкилләре керергә тиеш, шулай ук Министрлык вәкилләре дә керергә мөмкин.

Индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

индивидуаль проектны гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән чараларның педагогик әһәмияте;

эш бирүче тарафыннан нәтиҗәләре раслаган индивидуаль проектта каралган максатчан (шул исәптән арадаш) күрсәткечләргә ирешүдә чагыла торган грант алучының педагогик эшчәнлеге нәтиҗәлелеге.

Грант алучы тарафыннан әлеге хисаплар тапшырылмау грант түләүне туктатуга һәм Килешүне өзүгә, Килешү өзелгән грант алучы тарафыннан, әлеге Нигезләмәнең 20 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәләренә ирешмәүгә бәйле рәвештә, элек түләнгән грант суммасын алга таба кире кайтаруга китерә.

20. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучы тарафыннан грантлар бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

21. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәдә һәм төзелгән Килешүдә билгеләнгән грантлар бирү шартлары һәм тәртибе бозылу факты ачыкланган очракта, грант алучы Министрлыкның язма таләпләрен алган көннән 30 календарь көн эчендә алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемена ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

22. Грантны нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Безнең яңа укытучы»
гранты турындагы
нигезләмәгә кушымта

Форма

# Уку һәм дәрестән тыш уку эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен файдалану буенча индивидуаль проектның тасвирламасы

1. Уку һәм дәрестән тыш уку эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру ысулларын һәм технологияләрен куллану буенча индивидуаль проект (алга таба – проект) исеме:

______________________________________________________________

2. Проектны гамәлгә ашыра башлаган вакыттагы хәлгә карата гомуми тасвирнамә (иң күбе бер бит):

______________________________________________________________

3. Проектның максатлары һәм бурычлары: ______________________________________________

4. Чаралар планы (проектның төп чаралары тасвирнамәсе, этаплары һәм сроклары):

| Т/с | Гамәлгә ашыру этабы | Чараның исеме | Гамәлгә ашыру сроклары | Планлаштырыла торган нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

5. Проектның кирәклеген нигезләү: ______________________________________________

6.Проектта катнашучылар: ______________________________________________

7. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгы:

| Т/с | Нәтиҗәлек күрсәткече | Күрсәткеч зурлыгы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Кушымталар (видеоматериаллар, фотосурәтләр, басма продукция һ.б.) электрон һәм басма рәвештә тапшырыла.

______________________________________________ /______________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) (имза)

______________________________